**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**19.12.2019** г. Казань № **2544**

Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки өлешчә эшкә сәләтле дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү һәм аңа опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типлаштырылган административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июленнән № 210-ФЗ «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга, 2004 елның 27 февраленнән № 8-ЗРТ «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында», 2008 елның 20 мартыннан № 7-ЗРТ «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы законнарына, 2010 елның 2 ноябреннән № 880 «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләп чыгару һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына туры китереп б о е р а м:

1. Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки өлешчә эшкә сәләтле дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү һәм аңа опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән типлаштырылган административ регламентын расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары А.Р. Абашевка йөкләргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыгарылган көннән башлап үз көченә керә.

Министр М.Н. Садыйков

2019 елның «19» декабре № 2544
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы белән расланган

Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки өлешчә эшкә сәләтле дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү һәм аңа опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типлаштырылган административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки өлешчә эшкә сәләтле дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү һәм аңа опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте (алга таба - дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гриаз бирүчеләр: ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителмәгән, опека яки попечительлек билгеләү мизгеленә гражданнарның гомеренә яки сәламәтлегенә каршы аңлы җинаять кылган өчен хөкем ителмәгән һәм опекун яки попечитель булырга теләк белдергән балигъ булган эшкә сәләтле гражданнар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы _________________________муниципаль районы (шәһәр округы) (алга таба – опека һәм попечительлек органы) тарафыннан, опека яки попечительлек билгеләүгә мохтаҗ булган затның яисә опекун яки попечитель булырга теләк белдергән затның яшәү урыны буенча күрсәтелә.

1.3.1. Опека һәм попечительлек органының урнашу урыны: _________________ур., _____ йорт, каб. __.

Опека һәм попечительлек органының эш графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала, көн саен, дүшәмбе-пәнҗешәмбе ____ башлап ____кадәр, җомга ____ башлап ____кадәр, төшке аш ____ башлап ____кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы ______________________________________.

Җәмәгать транспорты белән _______________тукталышка кадәр бару.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документ буенча (яки ирекле).

1.3.2. Белешмә телефоннары:

1.3.3. Татарстан Республикасы________________________муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитетының (алга таба – Башкарма комитет) рәсми сайтының адресы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба –«Интернет» челтәре): http://www _________tatarstan.ru .

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны алырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен опека һәм попечительлек органы биналарында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст мәгълүматларын үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» челтәре аша;

Татарстан Республикасы___________муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитетының (алга таба – Башкарма комитет) рәсми сайтында (http://www____ tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://gosuslugi.ru/);

3) опека һәм попечительлек органына телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) опека һәм попечительлек органына язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Башкарма комитетның, опека һәм попечительлек органының урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайты адресы, шулай ук электрон почтасы турында мәгълүмат Башкарма комитетның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында опека һәм попечительлек органы белгече тарафыннан урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3-2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (подпунктларында) булган дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала;

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге документлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 1994, №32, 3301 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – РФ ГК);

- Россия Федерациясе Салым кодексы (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 1998, № 31, 3824 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – РФ СК);

- Россия Федерациясе Гражданлык процессуаль кодексы (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2002, №46, № 4532 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – РФ ГПК);

- Россия Федерациясе Торак кодексы (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2005, № 1 (1 өлеш), 14 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – РФ ТК);

- 1992 елның 2 июленнән № 3185-I номерлы «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнарның хокуклары гарантияләре турында» Россия Федерациясе Законы (Россия Федерациясе «Халык депутатлары Советы һәм Югары Советы Ведомостьлары», 1992, № 33, 1913 ст.) (алга таба – № 3185- I РФ Законы);

- 2006 елның 27 июленнән № 152-ФЗ «Персональ мәгълүматлар турында» Федераль закон (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2006, №31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – № 152-ФЗ Федераль закон);

- 2008 елның 24 апреленнән № 48-ФЗ «Опека һәм попечительлек турында» Федераль закон (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2008, №17, 1755 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – № 48-ФЗ Федераль закон);

- 2010 елның 27 июленнән № 210-ФЗ «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон);

- 2011 елның 6 апреленнән № 63-ФЗ «Электрон имза турында» Федераль закон (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2011, №15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон);

2012 елның 7 маеннан № 601 «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Россия Федерациясе Президентының Указы (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2012, № 19, 2338 ст.) (алга таба – № 601 Президентның Указы);

2010 елның 17 ноябреннән № 927 «Балигъ булган эшкә сәләтсез яисә өлешчә эшкә сәләтле булган гражданнарга карата опеканы һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2010, № 48, 6401 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба –№ 927 РФ карары);

2011 елның 7 июленнән № 553 «Дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны электрон документлар формасында оформить итү һәм бирү тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2011, № 29, 4479 ст.) (алга таба – № 553 РФ Хөкүмәтенең карары);

2011 елның 8 августыннан № 891н «2010 елның 17 ноябреннән № 927 Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары белән расланган балигъ булган эшкә сәләтсез яки өлешчә эшкә сәләтле булган гражданнарның опекуннары яки попечительләре булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау, исәпкә алу һәм хәзерләү кагыйдәләренең 17 пунктын гамәлгә ашыру турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының боерыгы (алга таба – № 891н боерык) (Россия газетасы, 2011, 28 сентябрь);

2017 елның 9 мартыннан № 250н «Балигъ булган эшкә сәләтсез яки өлешчә эшкә сәләтле булган гражданның опекуны яки попечителе булырга теләк белдергән якын туганының тормыш шартларын тикшерү турында акт формасын раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының боерыгы (алга таба – № 250н боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 2017, 27 июнь, бастырып чыгару номеры: 0001201706270021);

2004 елның 27 февраленнән № 8-ЗРТ «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, № 43-44, 2004, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – № 8-ЗРТ ТР Законы);

2008 елның 20 мартыннан № 7-ЗРТ «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен

бирү турында» Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, №60-61, 2008, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – № 7-ЗРТ ТР Законы);

20 ___елның________№____ ___________белән расланган Татарстан Республикасы ___________муниципаль районының (шәһәр округының) башкарма комитеты Уставы (алга таба – Устав);

20 ___елның________№____ ___________белән расланган Татарстан Республикасы ___________муниципаль районының (шәһәр округының) башкарма комитеты турындагы Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

20 ___елның________№____ ___________белән расланган Татарстан Республикасы ___________муниципаль районының (шәһәр округының) __________башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы турында Нигезләмә (алга таба – Бүлек турында Нигезләмә);

20 ___елның________№____ ___________белән расланган Татарстан Республикасы ___________муниципаль районының (шәһәр округының) башкарма комитетының эчке хезмәт тәртибе Кагыйдәләре (алга таба - Кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган гражданнарны урнаштыру формасы, бу очракта опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекага алынганнарның вәкилләре булып торалар һәм опекага алынганнар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрен яклап барлык кирәкле гамәлләрне башкаралар;

- попечительлек - суд тарафыннан эшкә сәләтлелек буенча чикләнгән гражданнарны урнаштыру рәвеше, бу очракта опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булган опекага алынганнарга РФ ГК 30 статьясына туры китереп гамәлләр кылу өчен ризалык бирергә тиешләр;

- опекага алынган гражданин – үзенә карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин;

- эшкә сәләтсез гражданин – РФ ГК 29 статьясында каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган гражданин;

- өлешчә эшкә сәләтле – РФ ГК 30 статьясында каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшкә сәләтлелектә чикләнгән гражданин;

- техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан ясалган һәм документка кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте нәтиҗәсе), белешмәләр нинди документлар нигезендә кертелгән, шул документлардагы белешмәләргә тәңгәл килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә охшаш хата);

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны - 2012 елның 22 декабреннән № 1376 «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пунктына туры китереп, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл

җирлегендә булдырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) астында № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запрос аңлашыла. Гаризаның тәкъдим ителгән формасы әлеге Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына булган таләпнең атамасы | Стандартка булган таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив-хокукый акт |
| --- | --- | --- |
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки өлешчә эшкә сәләтле дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү һәм аңа опекун яки попечитель билгеләү | РФ ГК;<br>№ 48-ФЗ Федераль закон;<br>Балигъ булган эшкә сәләтсез яки өлешчә эшкә сәләтле булган гражданнарның опекуннары яки попечительләре булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу, исәпкә алу һәм хәзерләү кагыйдәләре; № 927 РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган (алга таба – № 927 РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган Кагыйдәләр) |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Опека яки попечительлек билгеләүгә мохтаҗ булган затның яисә опекун яки попечитель булырга теләк белдергән затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы ______________муниципаль районының (шәһәр округының) башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге | Устав;<br>№ 7-ЗРТ ТР Законы 1 ст.;<br>№ 8-ЗРТ ТР Законы 3 ст.;<br>№ 48-ФЗ Федераль законының 11 ст.;<br>№ 927 РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган Кагыйдәләрнең 4, 4' п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсен тасвирлау | Опека (попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты җитәкчесенең карары (№ 1 кушымта) һәм билгеләнгән үрнәктәге таныклыкны бирү (№ 3 кушымта) яки опека (попечительлек) билгеләүдән һәм опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар | РФ ГК;<br>№ 48-ФЗ Федераль закон;<br>№ 927 РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган Кагыйдәләрнең 9 п.;<br>№ 8-ЗРТ ТР Законы |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итәргә кирәклекне исәпкә алып; дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору срогы, туктатылуы Россия Федерациясе законнары җыелмасы белән каралган булган очракта; дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (юнәлтү) срогы | Гаризаны һәм документларны теркәү көненнән башлап 15 календарь көне.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең срогын туктатып тору каралмаган.<br>Гаризада күрсәтелгән элемтә (почта аша, электрон адреска) юлы белән дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булып торган документларны юнәлтү дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен оформить итү һәм теркәү көнендә башкарыла. | № 8-ЗРТ ТР Законы;<br>№ 927 РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган Кагыйдәләрнең 9 п. |
| 2.5. Гариза бирүче тарафыннан бирелергә тиешле, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган, норматив хокукый актларга | Гариза (№ 2 кушымта).<br>Эш урыныннан соңгы 12 айда вазыйфасы һәм уртача хезмәт хакы күрсәтелгән справка, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган гражданнар өчен – керемнәрне раслаучы башка документ | РФ ГК;<br>РФ СК;<br>№ 48-ФЗ Федераль законның 10 ст.;<br>№ 927 РФ Хөкүмәтенең |

| | | |
|---|---|---|
| туры китереп дәүләт хезмәтен һәм хезмәтләрен күрсәтү өчен кирәкле булган документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе. | (пенсионерлар өчен – пенсия таныклыгының күчермәләре) (бирелгән көннән башлап ел дәвамында кабул ителә).<br>Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә бирелгән, опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинны тикшерү нәтиҗәләре буенча сәламәтлеге торышы турында медицина бәяләмәсе (бирелгән көннән башлап 3 ай эчендә кабул ителә).<br>Никах турында таныклыкның күчермәсе (опекун булырга теләк белдергән гражданин өйләнгән булса).<br>Гаиләдә опекун булырга теләк белдергән гражданин белән бергә яшәүче 10 яшькә җиткән балаларның фикерен исәпкә алып, гаиләнең балигъ әгъзаларының опекага алынган балигъ гражданинның опекун белән бергә яшәвенә язма ризалыгы (опекун тарафыннан опекага алынган балигъ гражданинның опекун гаиләсе белән бергә яшәве турында карар кабул ителүе очрагында).<br>Опекун булырга теләк белдергән гражданинның хәзерләнүне № 927 РФ Карары белән расланган Кагыйдәләр белән билгеләнгән тәртиптә узуы турында документ.<br>Автобиография.<br>Балигъ булган опекага алынучының опекуннары яки попечительләре булырга теләк белдергән, опекун булырга билгеләнү турында | карарының 4, 4' п. |

| | | |
|---|---|---|
| | гаризаны бирү көненә 10 елдан да ким булмаган вакыт эчендә аның белән яшәгән ата-аналары, әбиләре, бабайлары, абыйлары, апалары, балалары һәм оныклары (алга таба – опекун булырга теләк белдергән якын туганнары) яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органына түбәндәге документларны тапшыралар:<br>1) гариза (кушымта № 2);<br>2) балигъ булган опекага алынучы белән туганлыкны раслаучы документлар;<br>3)Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы белән билгеләнә торган тәртиптә бирелгән, опекун булырга теләк белдергән гражданинны медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча аның сәламәтлеге торышы турында медицина бәяләмәсе (аны бирү көненнән соң 3 ай эчендә кабул ителә);<br>4) никах турында таныклыкның күчермәсе (опекун булырга теләк белдергән якын туганы өйләнгән булса).<br>Гариза бирүче паспорт яки шәхесне таныклаучы башка документ бирә.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын опека һәм попечительлек органына шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәп бирелгән законда | |

| | | |
|---|---|---|
| | билгеләнгән тәртиптә расланган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан, ышаныч язуы нигезендә);<br>почта аша тапшыру турында белдерү кагәзе белән.<br>Шулай ук гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша гади электрон имза куелган электрон документ рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Гариза бирүче тәкъдим итәргә хокукы булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган хезмәтләр күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында килеп чыга:<br>гариза бирүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр яки торак йорттан файдалану хокукын раслаучы документ яисә торак урынына милек хокукы, һәм опекун булырга теләк белдергән гражданинның яшәү урыныннан финанс шәхси счеты күчермәсе (вәкаләтле органнарда);<br>эчке эшләр органнары тарафыннан бирелә торган, опекун булырга теләк белдергән гражданинның гражданнар тормышына һәм | № 927 РФ Хөкүмәте белән расланган Кагыйдәләрнең 6'п. |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе; әлеге документлар карамакта булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы, яисә оешма | сәламәтлегенә аңлы рәвештә җинаять кылган өчен хөкем ителмәгән булуы турында справка;<br>тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан бирелә торган, торак биналарның санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында справка (Татарстан Республикасы буенча Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең идарәсендә);<br>Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнары яки пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башка органнар тарафыннан бирелә торган, пенсия алуны раслаучы справка, – опекун булырга теләк белдергән пенсионер булучы гражданинга карата;<br>опекун булырга теләк белдергән якын туганның балигъ булган опекага алынучы белән аңа 18 яше тулганчы вакытта тиешсез мөгаләмәдә булуы турындагы фактларның булмавы турында опека һәм попечительлек органнары бәяләмәсе.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган, әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән документларны алу ысуллары һәм аларны бирү тәртибе.<br>Гариза бирүчедән таләп итергә тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яки | |

| | | |
|---|---|---|
| | аларны гамәлгә ашыру каралмаган документларны һәм мәгълүматны бирү яки гамәлләрне башкару;<br>Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яки) оешмалар карамагында булган документлар һәм мәгълүмат бирү, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен гариза бирүче тарафыннан түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүмат бирү;<br>№ 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда аларның булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яисә мәгълүматны таләп итү. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Бирелгән документларның әлеге Регламентның 2.5. п. күрсәтелгән документлар исемлеге белән туры килмәве;<br>2. Тапшырыла торган документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган төзәтүләр булу. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 3. Опекага яки попечительлеккә алынучы затның яисә опекун яки попечитель булырга теләк белдергән затның яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәү. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. | РФ ГК;<br>№ 48-ФЗ Федераль закон<br>№ 927 РФ Карары |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп. | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт турында запрос биргәндә һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чиратлылык билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт турында запросын теркәүнең срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза керү көнендә.<br>Ял көнендә (бәйрәм көнендә) электрон формада кергән запрос ял көненнән (бәйрәм көненнән) соң киләсе көндә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрослар тутыру өчен урыннарга, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге белән мәгълүмати стендларга, хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматны | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны оформить итү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Хезмәт күрсәтү урынына инвалидларның тоткарлыксыз үтеп керү мөмкинлеге, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу, шулай ук хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә. | |

| | | |
|---|---|---|
| урнаштыруга һәм оформить итүгә таләпләр, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнарга һәм Татарстан Республикасының законнарына туры китереп күрсәтелгән объектларның инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итү | Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтен алу мөмкинлегенең һәм сыйфатының күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләр саны һәм аларның озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр куллану белән, Федераль законның 15' статьясы белән каралган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) | Дәүләт хезмәте күрсәтүне алу мөмкинлегенең күрсәткечләре булып тора:<br>____________бинаның җәмәгать транспортына чыга алырлык зонада урнашуы<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчедән документларны кабул итү башкарыла торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә _______________ мәгълүмат ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;<br>гаризаларны электрон формада бирү мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарны инвалидлар өчен уңайлы итү;<br>инвалидларга хезмәтләрне башка затлар | |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәтне күрсәтү турында запрос (комплекслы запрос) ярдәмендә гариза бирүче сайлавы буенча (экстерриториаль принцип) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, җирле үзидарә органы башкарма җитәкчелек органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә дәүләт хезмәте алуның (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкин булуы яисә мөмкин булмавы | белән бертигез алу өчен комачаулаучы киртәләрне узып чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү һәм аларны бирү чиратлары;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүнең срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата дөрес түгел, игътибарсыз мөнәсәбәттә булуга шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара тәэсир итешүе күздә тотыла. Тәэсир итешү дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче ___________сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында алырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша, КФҮнең читтән торып эш урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип | |

| | | |
|---|---|---|
| | буенча һәм комплексым запрос составында күрсәтелми. | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелсә) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләре. | Консультация интернет-кабул итү бүлмәсе аша бирелергә мөмкин.<br>Гариза һәм документлар күчермәләре гариза бирүче тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | № 63-ФЗ Федераль закон<br>№ 210-ФЗ Федераль закон<br>№ 553 РФ Хөкүмәте карары |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклегенең тасвирламасы.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү;
- гариза һәм документлар кабул итү, аларны теркәү;
- дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү;
- опекун булырга теләк белдергән гражданинның яшәү шартларын тикшерү;
- опекун (попечитель) билгеләү турында карар кабул итү яки опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү;
- дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;
- техник хатаны төзәтү.

3.2. Гариза бирүегә консультация бирү.

3.2.1. Гариза бирүче опека һәм попечительлек органына (алга таба – Бүлек) шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, консультацияләр бирә.

Бүлек белгече гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү предметы буенча консультация бирә, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бланкын бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документлар составы, формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризалар һәм документлар кабул итү, аларны теркәү.

3.3.1. Гариза бирүченең шәхсән яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, яисә тапшыру турында белдерү кәгазе белән заказлы почта җибәрүе аша әлеге Регламентның 2,5 пунктында каралган гаризаны һәм документларны бирүе гариза һәм документларны кабул итү буенча административ процедураны башкаруны башлау өчен нигез булып тора.

Кабул итүне алып баручы Бүлек белгече башкара:

гариза бирүченең шәхесен билгеләү;

документларның булуын тикшерү;

бирелгән документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документлар күчермәләренең тиешенчә оформить ителүе, документларда бозып төзәтүләр, припискалар, сызып алынган сүзләр һәм башка килешмәгән төзәтмәләр булмау).

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, Бүлек белгече гаризаны кабул итү

датасы турында һәм аңа теркәп бирелә торган документларны билгеләү белән опись күчермәсен гариза бирү ысулына карап, гариза бирүчегә бирә, тапшыру турында белдерү кәгазе белән заказлы почта җибәрүе аша яки электрон формада җибәрә.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Бүлек белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, Бүлек белгече кергән гаризаны терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза (гариза бирүче мөрәҗәгате) кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза һәм документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша запрослар җибәрә:

гариза бирүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр бирү турында яки торак урыныннан файдалану хокукын яисә торак урынга милек хокукын раслаучы документ һәм опекун булырга теләк белдергән гражданинның яшәү урыныннан финанс шәхси счеты күчермәсе (вәкаләтле органнарга);

опекун булырга теләк белдергән гражданинның гражданнарның тормышына һәм сәламәтлегенә каршы уйланылган җинаять өчен хөкем ителмәгән булуы турында справка бирү турында (эчке эшләр органнарына);

торак биналарның санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында справка бирү турында (Татарстан Республикасы буенча Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең идарәсенә);

пенсионер булып торучы, опекун булырга теләк белдергән гражданинга карата пенсия алуын раслаучы справканы бирү турында (Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнарына яисә пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башка органнарга);

опекун булырга теләк белдергән якын туганның балигъ булган опекага алынучы белән аңа 18 яше тулганчы вакытта тиешсез мөгаләмәдә булуы турындагы фактларның булмавы турында опека һәм попечительлек органнары бәяләмәсен бирү турында (опека яки попечительлек билгеләүгә мохтаҗ булган затның элеккеге яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органнарына).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике көн эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турында запрос.

3.4.2 Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, законнар

белән билгеләнгән срокта соратып алына торган документларны (белешмәләрне) тапшыралар.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (белешмәләр) яисә документларны (белешмәләрне) бирүдән баш тарту турында белдерү.

3.5. Опекун булырга теләк белдергән гражданинның яшәү шартларын тикшерү.

3.5.1. Опекун булырга теләк белдергән гражданинны (опекун булырга теләк белдергән якын туганнарыннан тыш) опекун итеп билгеләү максатыннан, Бүлек белгече аның яшәү шартларын тикшерә, аның барышында Россия Федерациясе Гражданлык кодексында билгеләнгән опекун (попечитель) итеп билгеләнүгә комачаулык итүче шартлар булмау билгеләнә.

Опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинның яшәү шартларын тикшергәндә опека һәм попечительлек органы белгече торак-көнкүреш шартларын, гариза бирүченең шәхси сыйфатларын һәм мотивларын, аның опекун вазыйфаларын үтәүгә сәләтен, шулай ук аның гаилә әгъзалары арасында булган мөнәсәбәтләрне бәяли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура опекун яки попечитель булырга теләгән затның гаризасын теркәгәннән соң җиде көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинның яшәү шартларын тикшерү.

3.5.2 Тикшерү нәтиҗәләре опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинның яшәү шартларын тикшерү турында актта күрсәтелә (№ 4 кушымта) (алга таба – гражданинның яшәү шартларын тикшерү турында акт).

Тикшерү турындагы Акт 2 нөсхәдә оформить ителә, аларның берсе опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинга җибәрелә, икенчесе Бүлектә саклана.

Тикшерү турындагы актка карата опекун булырга теләк белдергән гражданин суд тәртибендә дәгъва белдерергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура тикшерү уздырылган көннән башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинның яшәү шартларын тикшерү турында акт.

3.5.3 Опекун булырга теләк белдергән якын туганны опекун итеп билгеләү максатларында, Бүлек белгече яшәү шартларын тикшерә, аның барышында Россия Федерациясе Гражданлык кодексы белән билгеләнгән опекун (попечитель) итеп билгеләнүгә комачаулаучы шартлар булмау билгеләнә.

Опекун булырга теләк белдергән гражданинның яшәү шартларын тикшергәндә опека һәм попечительлек органы торак-көнкүреш шартларын, гариза бирүченең шәхси сыйфатын һәм мотивларын, аның опекун вазыйфаларын үтәүгә сәләтен, шулай ук аның гаилә әгъзалары арасында булган мөнәсәбәтләрне бәяли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура опекун булырга теләк белдергән якын туганы гаризасын теркәгәннән соң җиде көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекун булырга теләк белдергән якын туганның яшәү шартларын тикшерү.

3.5.4. Тикшерү нәтиҗәләре опекун булырга теләк белдергән якын туганның яшәү шартларын тикшерү турында актта күрсәтелә (№ 8 кушымта) (алга таба – якын туганның яшәү шартларын тикшерү турында акт).

Тикшерү турындагы акт 2 нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинга җибәрелә, икенчесе Бүлектә саклана.

Тикшерү турындагы актка карата опекун булырга теләк белдергән гражданин суд тәртибендә дәгъва белдерергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура тикшерү уздырылган көннән соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекун булырга теләгән якын туганның яшәү шартларын тикшерү турында акт.

3.6. Опекун (попечитель) билгеләү турында карар кабул итү яки опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.6.1 Бүлек белгече опека һәм попечительлек комиссиясенә (алга таба – Комиссия) бирү өчен документлар пакетын формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: формалаштырылган һәм Комиссиягә карауга җибәрелгән документлар пакеты.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.2. Утырышта Комиссия опекун (попечитель) билгеләү яки опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Опекун (попечитель) итеп балигъ булган эшкә сәләтле гражданин гына билгеләнә ала. Шул ук вакытта аның әхлакый һәм башка шәхси сыйфатлары, опекун яки попечитель бурычларын үтәү сәләте, гариза бирүче белән опекага яки попечительлеккә мохтаҗ булган зат арасында булган мөнәсәбәтләр, мөмкин булса – опекага алынган кешенең теләге дә, исәпкә алынырга тиеш.

Опека һәм попечительлек буенча Комиссия утырышын үткәрү барышы, шулай ук аның бәяләмәсе утырыш протоколында теркәлә. Күрсәтелгән протоколлар Комиссия утырышлары протоколларын теркәү журналында теркәлә (№ 7 кушымта).

3.6.3 Комиссия гариза бирүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры китереп бирелгән документлар, әлеге Регламентның 3.4.1, 3.4.2 пунктларына туры китереп алынган белешмәләр (документлар) һәм гражданинның яшәү шартларын тикшерү турында акт (якын туганның яшәү шартларын тикшерү турында акт) нигезендә опекун (попечитель) билгеләү турында карар яисә опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Комиссия тарафыннан опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар түбәндәге нигезләрнең берсе булса да булган очракта кабул ителә:

- гариза бирүче тарафыннан бирелгән документларда дөрес булмаган яки ялгыш мәгълүматлар ачыкланса;

- гариза бирүченең әлеге Регламентның 1.2 пункты таләпләренә туры килмәве (суд тарафыннан гариза бирүченең эшкә сәләтсез яки өлешчә сәләтле дип танылуы, гариза бирүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүе, гариза бирүченең опека һәм попечительлек билгеләү вакытына гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә карата аңлы җинаять кылган өчен хөкем ителүе булу);

- конкрет гражданинны опекун яки попечитель итеп билгеләү опекага алынучының мәнфәгатьләренә туры килми торган шартлар ачыклану (закон тарафыннан билгеләнгән опекун бурычларын тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелгән булу; опекун бурычларын үтәүгә комачаулаучы авыру белән интегү; даими яшәү урыны булмау, санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга җавап бирми торган торак урыннарда яшәү);

